**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**Сарман авыл җирлеге**
**423350 Сарман авылы, М.Жэлил ур., 63**
**тел.: 2-43-67, 2-45-38**
**E - mail: Sar.sar @ tatar.ru**
ИНН/КПП 1636001266/163601001

**Сармановское сельское поселение**
**САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
**423350 с. Сарманово, ул.М.Джалиля, 63**
**тел.: 2-43-67, 2-45-38**
**E – mail: Sar.sar @ tatar.ru**
ИНН/КПП 1636001266/163601001

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

23 ноября 2018 г. № 20

«Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлегенең 2019 елга һәм 2020 һәм 2021 еллар планлы чорына бюджеты турында» карар проекты хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Сарман авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Сарман авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советына таянып, карар итте:

1. «Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлегенең 2019 елга, 2020 һәм 2021 еллар план чорына бюджеты турында» карар проектын беренче укылышта кабул итәргә.

2.Әйтелгән тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне исәпкә алып, аның өстендә эшне дәвам итәргә.

3. «2019 елга һәм 2020 һәм 2021 еллар план чорына Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлеге бюджеты турында» карар проектына кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карап тикшерү буенча эшче төркем төзү:

1.Нуруллин Рөстәм Рифгать улы-төркем җитәкчесе;

2.Сәлимгәрәев Равил Фазыл улы-төркем әгъзасы;

3.Мөхәммәдиев Рөстәм Әхнәф улы-төркем әгъзасы.

4.Карар проектына гражданнарның тәкъдимнәре эш төркеменә Татарстан Республикасы, Сарман авылы, Ленин урамы, 52 адресы буенча язма рәвештә җибәрелә.

5. «Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлегенең 2019 елга һәм 2020 һәм 2021 еллар план чорына бюджеты турында» карар проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү 2018 елның 10 декабрендә 15.00 сәгатьтә киноучреждение конференцзалында (адресы: Сарман авылы, Ленин урамы, 28) була.

6.Эшче төркемгә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлеге Советы депутатлары төзәтмәләрен һәм карар проектына гражданнарның тәкъдимнәрен өйрәнергә һәм гомумиләштерергә, карар проектын эшләп бетерергә һәм аны Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлеге Советы каравына 2018 елның 15 декабренә кадәр кертергә.

7.Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы»муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

8.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Сарман Муниципаль Районы Советы Рәисе

авыл җирлеге башлыгы муниципаль район башлыгы Ф. М. Хөснуллин